ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 11-49/тко

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Лаишево» муниципаль унитар предприятиесенең каты коммуналь калдыкларны күмү буенча җайга салынулы эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Лаишево» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2018-2020 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында» 01.12.2017 № 10-82/кс;

«Лаишево» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-82/кс карары белән расланган озак сроклы чик тарифларга 2019 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында» 21.11.2018 № 10-93/кс.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәлдә була, дип билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Л.П.Борисова